**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 15 апрелендәге 1172 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 84 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:050148:15;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы;
- билгеләү максаты: электр белән тәэмин итүне (технологик тоташтыруны) оештыру өчен;
- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округы Генераль планы, электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында 2024 елның 22 июлендәге 2024/КЭС/510/Т693 номерлы шартнамә.

2. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлегенең хокук ияләре белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;


7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аңардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 15 апрелендәге
1172 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| Масштаб 1:250<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа барлыкка килгән характерлы нокта |
| | Сервитутлар (Статуссыз) |
| | Җир кишәрлекләре |
| | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| 16:50:050148 | кадастр кварталы |
| 16:50:050148:15 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________________